**Министерство сельского хозяйства Российской Федерации**
**федеральное государственное бюджетное образовательное учреждение высшего образования «Казанская государственная академия ветеринарной медицины имени Н.Э. Баумана»**

«УТВЕРЖДАЮ»
проректор по учебно-воспитательной работе и молодежной политике
_______________ /Л.Р. Загидуллин/
« 20 » февраля 2024 г.

# МЕТОДИЧЕСКИЕ РЕКОМЕНДАЦИИ ПО ПРОВЕДЕНИЮ ПРАКТИЧЕСКИХ ЗАНЯТИЙ ПО ПРЕДМЕТУ РОДНОЙ ЯЗЫК (ТАТАРСКИЙ)

**Среднее профессиональное образование**
**Наименование специальности:** 36.02.01 Ветеринария
**Квалификация выпускника:** ветеринарный фельдшер
**Форма обучения:** очная
**Уровень образования:** базовый

Казань 2024

УДК 811.512.145
ББК 81.632.3
М 54

М54. Методические рекомендации по проведению практических занятий дисциплине «Родной (Татарский) язык» для студентов факультета среднего профессионального образования по специальности 36.02.01 Ветеринария / Г.Х. Якупова // ФГБОУ ВО Казанская ГАВМ. - 2024. - 19 с.

Рецензенты:
заведующий отделом токсикологии ФГБНУ «ФЦТРБ-ВНИВИ», доктор биологических наук Э.И. Семенов;
профессор кафедры технологии производства и переработки с/х продукции ФГБОУ ВО Казанская ГАВМ, доктор биологических наук О.А. Якимов

Методические рекомендации при проведении практических занятий предназначены для закрепления теоретических знаний и приобретение необходимых практических навыков и умений по разделу «Синтаксис» дисциплины ОГСЭ.06 «Татарский язык», составлены в соответствии с учебным планом и рабочей программой дисциплины по специальности 36.02.01 Ветеринария среднего профессионального образования.

Рассмотрено и одобрено:
на заседании методической комиссии факультета СПО протокол №2 от «20» февраля 2024 г.

УДК 811.512.145
ББК 81.632.3
© Г.Х. Якупова., 2024
©Федеральное государственное
бюджетное образовательное учреждение
высшего образования
«Казанская государственная академия
ветеринарной медицины имени Н.Э. Баумана»,
2024 год

Содержание


| | | Стр. |
|---|---|---|
| | Введение | 4 |
| 1. | Название теоретических и практических занятий | 6 |
| 2. | Синтаксис. Простое предложение | 7 |
| | Практическое занятие № 1 Простое предложение | 7 |
| 3. | Сложное предложение | 15 |
| | Практическое занятие № 2 Сложное предложение | 15 |

## Введение

Методические рекомендации по выполнении практических занятий по учебной дисциплине составлены в соответствии с учебным планом и рабочей программой дисциплины по специальности 36.02.01 Ветеринария среднего профессионального образования. В соответствии с рабочей программой на изучение учебной дисциплины ОГСЭ.06 «Родной (Татарский) язык», раздела «Синтаксис» отведено 4 часа на проведение теоретических и практических занятий.

Цель проведения теоретических и практических занятий: формирование функциональной грамотности и всех видов компетенций.

Задачи: - обобщение, систематизация, углубление, закрепление полученных теоретических и практических знаний по татарскому языку; совершенствование умений обучающихся осмысливать закономерности языка, правильно, стилистически верно использовать языковые единицы в устной и письменной речи в разных речевых ситуациях.

В программу включено содержание, направленное на формирование у обучающихся общих компетенций, необходимых для качественного освоения ОПОП СПО. Обучающийся должен обладать общими компетенциями:

| Код ПК, ОК | Умения | Знания |
|---|---|---|
| ОК 04<br>ОК 05<br>ОК 09 | - организовывать работу коллектива и команды;<br>- взаимодействовать с коллегами, руководством, клиентами в ходе профессиональной деятельности;<br>- грамотно излагать свои мысли и оформлять документы по профессиональной тематике на государственном языке, проявлять толерантность в рабочем коллективе;<br>- понимать общий смысл четко произнесенных высказываний на известные темы (профессиональные и бытовые), понимать тексты на базовые профессиональные темы;<br>- участвовать в диалогах на знакомые общие и профессиональные темы;<br>- строить простые высказывания о себе и о своей профессиональной деятельности;<br>- кратко обосновывать и объяснять свои действия (текущие и планируемые);<br>- писать простые связные сооб- | - психологические основы деятельности коллектива, психологические особенности личности;<br>- основы проектной деятельности;<br>- особенности социального и культурного контекста;<br>- правила оформления документов и построения устных сообщений;<br>- правила построения простых и сложных предложений на профессиональные темы;<br>- основные общеупотребительные глаголы (бытовая и профессиональная лексика);<br>- лексический минимум, относящийся к описанию предметов, средств и процессов профессиональной деятельности;<br>- особенности произношения;<br>- правила чтения текстов профессиональной направленности;<br>- особенности профессиональной документации на государственном и иностранном языках. |

| | | |
|---|---|---|
| | щения на знакомые или интересующие профессиональные темы;<br>- пользоваться профессиональной документацией на государственном и иностранном языках. | |

# 1. НАЗВАНИЕ ТЕОРЕТИЧЕСКИХ И ПРАКТИЧЕСКИХ ЗАНЯТИЙ

| Наименование раздела (темы) | Практическая работа | Содержание практической работы | Количе-ствочасов |
|---|---|---|---|
| **Раздел 4. Синтаксис. Простое предложение. Сложное предложение** | | | |
| Синтаксис. Простое предложение | Практическое и лабораторное занятие<br>Синтаксис. Простое предложение | Синтаксис простого предложения. Утвердительные и отрицательные предложения. Типы предложений по цели высказывания. Главные члены предложении. Второстепенные члены предложения. | 2 |
| Сложное предложение | Практическое и лабораторное занятие<br>Сложное предложение | Сложносочиненное предложение. Средства сочинительной связи между предложениями. Сложноподчиненное предложение. Средства выражения аналитической связи. Виды придаточных предложений. | 2 |

# ПРАКТИЧЕСКОЕ ЗАНЯТИЕ №1

# «СИНТАКСИС. ПРОСТОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ.

# СЛОЖНОЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ»

**Цель занятия:** получение теоретических и практических знаний по синтаксису простого предложения

Синтаксис – раздел языкознания, в котором изучаются синтаксические единицы – словосочетание и предложение.

Предложение (җөмлә) – грамматическая единица, содержащая в себе сообщение (Ямьле яз житте), вопрос (Сез академиядә укыйсызмы?), побуждение (И сабыйлар, эшләгез сез, иң мөкатдәс нәрсә - эш!). (Г.Т.)

***Утвердительные и отрицательные предложения (раслау һәм инкяр җөмләләр)***

В обоих сопоставляемых языках – русском и татарском по характеру связи между предметом речи и тем, что о нем сообщается, предложения делятся на утвердительные и отрицательные. Например: Мәкалә дөрес язылган. – утвердительное предложение. Бүген дәрес булмады. – отрицательное предложение.

***Типы предложений по цели высказывания***

*Повествовательные предложения. Хикәя җөмләләр.*

Повествовательное предложение является наиболее распространенным. Оно содержит сообщение о каких-либо фактах действительности, событиях, явлениях и т.д. Их особенность – относительная законченность мысли, которая передается спокойной, ровной интонацией, понижающейся в конце предложения и повышающейся на логически выделяемом слове. - Төньяктан салкын жил исеп тора.

*Вопросительные предложения. Сорау җөмләләр.*

Вопросительное предложение характеризуется вопросительной интонацией, логическим ударением на вопросительном местоимении или на слове с вопросительной частицей –мы/ -ме: Сез кайда укыйсыз?

*Повелительное предложение. Боерык җөмлә.*

Повелительное предложение характеризуется употреблением глагола в повелительном наклонении в функции сказуемого: Син уйлап эшлә.

*Восклицательное предложение. Тойгылы җөмлә.*

Восклицательное предложение характеризуется часто инверсией членов предложения, употреблением междометий, повторов, обращений, эмоциональных слов, восклицательной интонацией: Яшәсен тынычлык!

**Главные члены предложения (Җөмләнең баш кисәкләре)**

К ним относятся подлежащее (ия) и сказуемое (хәбәр).

Подлежащее обозначает предмет, признак, который назван сказуемом. Подлежащее выражается именем существительным или другими частями речи в значении существительного.

Сказуемое выражает действие, состояние или признак подлежащего. Сказуемое обычно выражается глаголом. Оно может быть выражено также именем существительным, прилагательным, числительным, именем действия.

**Второстепенные члены предложения (Иярчен кисәкләр)**

Грамматическую основу предложения поясняют второстепенные члены предложения – это дополнение, определение, обстоятельство, пояснение.

Определение – второстепенный член предложения, обозначающий признак предмета и отвечающий на вопросы нинди? кайсы? кемнең, нәрсәнең? ничәнче? кайдагы? Определение может быть выражено всеми самостоятельными частями речи и предикативными словами.- Бу яшьләр республикабызнын төрле почмакларыннан килгәннәр.

Дополнение – второстепенный член предложения, выражающий предмет, на который направлено действие, отвечает на вопросы всех шести падежей: кем? нәрсә? кемнең? нәрсәнең? кемгә? нәрсәгә? кемне? нәрсәне? кемнән? нәрсәдән? кемдә? нәрсәдә? Дополнения обычно выражаются существительным или местоимением в косвенном падеже. - Мин бу китапны укыйм.

Обстоятельство – это второстепенный член предложения, поясняющий слово со значением действия (глагол) или признака (прилагательное, наречие), обозначающий время, место, причину, цель, меру и степень, образ (способ), условие и уступительность действия. Различают следующие виды обстоятельств:

- урын хәле (обстоятельство места) обозначает место, где осуществляется, куда направлено и откуда происходит действие: Без авылга кайтабыз.

- вакыт хәле (обстоятельство времени) обозначает время совершенствия действия или время существования признака: Бүген көн салкын.

- сәбәп хәле (обстоятельство причины) обозначает причину совершения действия или существования признака: Озак йорү сәбәпле, бүген ул соң кайтты.

- максат хәле (обстоятельство цели) обозначает цель совершения действия: Урманга җиләккә киткән.

- шарт хэле (обстоятельство условия) обозначает условие, при котором могло совершиться действие. – Дәресләрен вакытында карап бетерсә, ул урамга чыгачак.

- кире хэл (обстоятельство уступительности) обозначает действие, которое совершается вопреки действию, выраженному главным членом предложения – сказуемым: Укыса да белми.

- күләм-чама хәле (обстоятельство меры и степени) обозначает меру и степень действия или признака: Ул рухи яктан шактый көчле кеше.

- рәвеш хәле (обстоятельство образа действия) обозначает способ совершения действия: Кынгырау төсле чылтырап, басу өстендә тургайлар сайрый.

**Пояснение (аныклагыч)**

Пояснение – второстепенный член предложения, находящийся после поясняемого слова и дающий дополнительные сведения (пояснения) о нем. (Другие второстепенные члены – определения, дополнения и обстоятельства – находятся перед главным словом – существительным и глаголом.)

Пояснительная интонация и обязательная постпозиция – находится всегда после поясняемого слова: Алмаз – дүртенче курс студенты – башка шәһәргә китте.

Союз ягъни, союзные слова башка төрле (башкача) әйткәндә, дөресрәге, мәсәлән, аеруча, бигрәк тә и др.: Бүген, 1 июнь көнне, студентлар имтиханнар тапшыра башлады.

**Задания для обучающегося:**

**ГАДИ ҖӨМЛӘ**

***Өзекне укыгыз. Ия һәм хәбәрне табыгыз. Иянең нинди сүз төркемнәре белән белдерелүен әйтегез. Дүртенче җөмләне рус теленә тәрҗемә итегез.***

1. Күпчелек ташбакалар тропикларда тереклек итә. 2. Еланнарның барысы да, кимерүче хайваннарны аулап, бик зур файда китерәләр. 3. Ташбакаларда күрү һәм ис сизү яхшы үсеш алган. 4. Сукмак буйлап барганда, без әвернәле үрмәкүч пәрәвезен күрәбез. 5. Юллар салу, сәнәгать биналары һәм башка корылмалар төзү үзләре биләп торган мәйданга гына тугел, шулай ук әйләнә-тирәгә тәэсир итә. 6. Язын кошларның барысы да җанлана. Аккошлар белән үрдәкләрнең күбесе аларның төп азыклану урыннары булган сулыклары туңа башлагач ташлап китәләр, һәркем әйләнә-тирәсен үзенчә күрә, үзенчә тасвирлап бирә.

***Гади һәм тезмә ияләрне әйтегез. Үсемлек исемнәре рус телендә ничек әйтелә?***

1. Давыл чәчәге үскән урыннар алтынсыман төс биреп, ерактан күренеп торалар. 2. Гөлҗимеш май-июньдә чәчәк ата, җимешләре август-сентябрьдә өлгерә. 3. Аю колагы үсемлеге элек-электән ялкынсынуга каршы һәм дезинфекцияләүче чара буларак кулланыла. 4. Артыш — ике өйле үсемлек. 5. Эт шомырты Татарстанның барлык урманнарында да очрый. 6. Колмак республикабызньң киң яфраклы дымлы урманнарында, вак куаклы әрәмәлекләрдә, елга үзәннәрендә очрый. 7. Нәүрүзгөл элек-электән күңел күтәргеч, тирләткеч дару буларак кулланылган. 8. Кызылтүш - бик хәрәкәтчән, каурыйлары сары, ал һәм ак төсләр белән бизәлгән матур кош.

ҖӨМЛӘНЕҢ ИЯРЧЕН КИСӘКЛӘРЕ. АЕРГЫЧ

***Җөмләләрдән аергычларны табыгыз. Аларның нинди сүз төркеме белән белдерелүен әйтегез.***

1. Кышкы ачы салкыннарда азык булмаудан һәм салкыннан күп кенә кошлар

һәлак була. 2. Бөтен дөньяда атлы спорт зур популярлык казанды. 3. Зоотехниклар мехлары төрле төстәге җәнлекләр барлыкка китерү белән шөгыльләнә. 4. Ак, кара, көмеш сыман зәңгәрсу, энҗе төсендәге чәшкеләр китереп чыгарылды. 5. Пошиларның озын аяклары тирән карда һәм сазлыклы урыннарда йөрү өчен җайлашканнар. 6. Кошларга туклыклы һәм яхшы сыйфатлы катнаш азыклар ашаталар. 7. Су кошларының күбесе җирдә әкрен һәм җайсыз йөри. 8. Кәлтәнең бөтен тәне мөгез кабырчыклы коры тире белән капланган.

***Түбәндәге аергычларны тиешле урыннарына куеп, җөмләләрне күчереп языгыз.***

1. Татарстанда кара җиләк дымлы (...) урманнарда үсә. 2. Сары мәтрүшкә (...) урманнарда, аланнарда, куаклар арасында, көтүлекләрдә, печәнлекләрдә, тау битләрендә үсә. 3. Агулы үсемлекләр (...) якларга киткән саен күбрәк очрыйлар. 4. Тозлы туфракларда да агулы үсемлекләрнең, (...) туфраклы җирләргә караганда, күбрәк үсүе билгеле. 5. Рус ракитнигы ылыслы урманнарда, далаларда, дымлы тау сыртларында, һәрвакыт (...) туфракларда үсә. 6. Елга кысласы чиста (...) суларда — елга, инеш, күлләрдә тереклек итә. 7. Кошчылык — терлекчелекнең (...) сыйфатлы продуктларны күп бирә торган әһәмиятле тармагы. 8. Кошларның күбесе бик (...) сайрый, үзләренең җырлары белән алар кешенең күңелен ача, рухландыра.

Сайлап алу өчен сүзләр: төче, якты, ылыслы, жылы, матур, яхшы, комлы, кара.

ТӘМАМЛЫК

***Тәмамлыкларны табыгыз, төрләрен билгеләгез. Җөмләләрне рус теленә тәрҗемә итегез.***

1. Кортлар нектарны кәрәз күзәнәкләренә бушата, һәм шунда нектар балга әйләнә. 2. Суда кислород азайганда, балыклар өскә йөзеп чыга һәм һаваны авызы белән йота башлый. 3. Кешеләр табигатьне буйсындырып, экологик системаларның тотрыклылыгын шактый дәрәҗәдә какшатты. 4. Сугарулы жирләрдә агулы химикатларны һәм минераль ашламаларны күп куллану тирә-юньне агулады. 5. Гөлҗимешне еш кына витаминлы чәйләр җыелмасына кертәләр. 6. Аю баланын еш кына бакча һәм паркларда декоратив үсемлек буларак та үстерәләр. 7. Җәйнең икенче яртысында эшче кортлар кыш өчен бал туплыйлар. 8. Елан агуы медицинада дарулар әзерләү өчен файдаланыла. 9. Шул максат белән еланнарны махсус питомникларда асрыйлар.

ХӘЛ

***Мисаллардан урын хәлләрен табыгыз. Нинди сүз төркеме белән белдерелүен аңлатыгыз.***

1. Кошларны кырларга, җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчаларына якынрак иялэштерү уңышның артуына китерә. 2. Кайбер кошлар (мәсәлән, үрдәкләр, торналар) ояларын турыдан-туры жирдә коралар. 3. Наратбаш сай сулыкларда, сазлыкларда, елга-кул буйларында үсә. 4. Акулалар - диңгез һәм океаннарда киң таралган тиз йөзэ торган балыклар. 5. Озынлыгы 11 метрга җитә торган иң эре буар елан анаконда Көньяк Америкада тереклек итә. 6.

Очлы башлы бака кышлау өчен туфрак арасына яшеренә. 7. Кошлар, төркем-төркем булып, әкренләп көньякка таба күчә башлыйлар. 8. Күкшәләр имән һәм урман чикләвекләрен җир өстендәге чокырларга, мүк астына һәм агач куышларына яшереп куялар. 9. Дала һәм чүл кошлары азыкны жирдән, үсемлекләр арасыннан эзләп таба.

***Җөмләләрне укыгыз. Вакыт хәлләрен табып, иярттүче сүзгә нинди чаралар ярдәмендә иярүен аңлатыгыз.***

1. Язын кошларның барысы да җанлана һәм алар дәртләнеп сайрый башлыйлар. 2. Тукран көзен һәм кышын ылыслы агач күркәләренең орлыгын чүпләп ашый. 3. Ташбака кышын, башка барлык сөйрәлүчеләр кебек, йокыга тала. 4. Налим көзгә таба гына җанлана, декабрьдә яки январьда уылдык чәчә. 5. Бакалар елның җылы вакытында гына актив тереклек алып баралар. 6. Көз җитү белән, алар кышлау урынына күчеп китәләр. 7. Очарлык булгач кына, әти-әнисе кошчыкларын ашатмый башлый. 8. Апрель җиткәч, күктә бик биектә, өчпочмак рәвешендә төзелеп, торкылдашып торналар оча.

***Җөмләләрне күчереп языгыз, сәбәп һәм максат хәлләрен билгеләгез. Нинди сүз төркеме белән белдерелүләрен, бәйләүче чараларын әйтегез.***

1. Океан суының физик үзлекләре һәм химик составы шактый даими булганлыктан, алар тереклек ечен уңайлы тирәлек хасил итәләр. 2. Файдалы энергиянең шундый зур югалтулары аркасында азык чылбырлары бик озын була алмый: гадәттә алар 3-5 буыннан (азык дәрәҗәләреннән) тора. 3. Сулары аз аралашканлыктан, аскы катлаулар һәрвакыт салкын һәм алар кислородка ярлы. 4. С гиповитаминозы азыкта һәм организмда С витамины җитмәгәнлектән барлыкка килә. 5. Ревматизмны һәм башка авыруларны дәвалау өчен бал корты агуының файдалы үзлекләре бар. 6. Кайбер җайдакларны лабораторияләрдә үрчетәләр һәм кешегә зыян китерә торган бөҗәкләрне юк итү өчен иреккә чыгаралар. 7. Иң гади төзелешлеләрне һәм моллюскларны тау токымнарының яшен белү өчен файдаланалар. 8. Известьне шулай ук аммиаклы азотлы ашламаларны нейтральләштерү өчен дә кулланалар.

***Түбәндәге мисаллардан күләм хәлләрен табыгыз. Ияртүче сүзгә нинди чаралар ярдәмендә иярүен аңлатыгыз. Аю, байбак, дөя сүзләре рус телендә ничек әйтелә?***

1. Аю, байбак һәм башка хайваннар кышкы йокылары вакытында ике айдан артык су эчмиләр. 2. Дөяләр сусыз чүлләр кичкәндә, 10-12 көн буе эчми тора алалар. 3. Китта тире асты май катлавының калынлыгы 1 м га җитә, бу исә аңа поляр диңгезләрнең салкын суларында яшәргә мөмкинлек бирә. 4. Май таркалганда, углеводлар таркалгандагыга караганда, ике тапкыр күбрәк энергия аерылып чыга. 5. Күзәнәктәге аксым молекулалары «гомеренең дәвамлылыгы» 2-3 сәгатьтән алып берничә көнгә кадәр булуы беленгән.

***Халык сынамышларын укыгыз. Шарт хәлләрен табыгыз.***

1. Балыклар су өстендә уйнасалар, яңгыр булыр. 2. Аккош иртә килсә, яз начар булыр, озак торыр. 3. Кошлар кар өстенә төшсә, көн җылыта. 4. Умарта кортлары оясында шауласа, яңгыр булыр. 5. Кырмыскалар канатланса, яңгыр булыр. 6. Каргалар тоташ йөрсә, ашлык уңар. 7. Үрдәкләр түбән очса, тары уңар. 8. Карлыгач иртә килсә, көннәр тиз матурланыр. 9. Иртә күк

күкрәсә, ел яңгырлы килер. 10. Ат юлга ятса, буран булыр.

***Кире хәлләрне табыгыз. Аларның нинди чаралар ярдәмендә фигыльгә иярүен әйтегез.***

1. Буа әкәм-текәме суда яшәсә дә, атмосфера һавасын сулый. 2. Кайда гына булсак та — урмандамы, бакчадамы, басу яки болындамы – күбәләкләр иртә яздан алып көз азагына кадәр безнең игътибарны үзләренә җәлеп итәләр. 3. Куркыныч туганда, олы кошлар ояны бик нык саклыйлар, хәтта үзләреннән көчлерәк кош күренсә дә, куркыныч барлыгын белдереп һәм ярдәмгә чакырып кисәткеч тавыш бирәләр. 4. Җылы якларга очып китүче икенче бер кошлар, мәсәлән, сандугачлар, шәүлегәннәр, керәшәләр, оялаган урыннарында һава җылы һәм азык та күп булуга карамастан, кышлау өчен туган илләреннән бик иртә — җәй азагында ук кузгалалар. 5. Шулай да агулы үсемлекләрнең табигатьтә күп таралганлыгы мәгълүм. 6. Агулы үләннәрнең организмга тәэсир итү юллары бик катлаулы һәм күп төрле. Ләкин шуңа да карамастан, агулы матдәләр составына карап, үсемлекләрнең хайван организмына, аның төрле органнарына ничек тәэсир итүе билгеле.

## АНЫКЛАГЫЧ

***Аныклагыч һәм аныкланмышларны күчереп языгыз. Бәйләнеш төрләрен аңлатыгыз.***

1. Гидраның тәнендә һәм аеруча кармавычларында күп санлы үзенә бертөрле чаккыч, ягъни уклы күзәнәкләр урнашкан. 2. Эчке катлау күзәнәкләренең — эндодерманың — кыскаручан мускул җепселләре бар. 3. Рефлекс бер-бер артлы килә торган өч этаптан: тынычсызлануны кабул итү, шул тынычсызланудан булган ярсынуны нерв күзәнәкләре буенча тапшыру һәм нинди дә булса хәрәкәт белән организмның җавап бирү реакциясеннән тора. 4. Кешедә каты авыру — бизгәкне канда урнашкан бизгәк паразиты тудыра. Фораминифералар — диңгез тамыраяклылары да амебаларга керә. Алардан кыйммәтле төзү материалы — известьташ чыганаклары барлыкка килгән. 5. Эвглена ике терле ысул белән туклана ала: яктыда — яшел үсемлекләр кебек, караңгыда, әзер органик матдәләрне үзләштереп, хайваннар кебек туклана. 6. Көз көне, салкыннар башлангач, амеба тукланмый башлый. 7. Шулай итеп, амеба организмына тышкы тирәлектән төрле матдәләр: азык, су, кислород кереп тора. 8. Систематиканың төп бурычы - хайваннарны төркемнәргә бүлү, ягъни аларны классификацияләү.

***Аныклагыч һәм аныкланмышларны табыгыз. Тыныш билгеләре кую кагыйдәләрен әйтегез.***

1. Җәйнең тырыш эшчеләре — бал кортлары — кышка әзерлекләрен тәмамлап киләләр. 2. Балыкның гәүдә өлешендә, умырткалык астында, зур тән куышлыгы бар, анда эчке органнар урнашкан. 3. Кешенең хуҗалык эшчәнлегенә зыян китерүче буынтыгаяклыларны биологик ысул белән басу күп кенә ерткыч бөҗәкләр (камка, кырмыскалар һ.б.), шулай ук паразит бөҗәкләр (мәсәлән, жайдак) ярдәмендә башкарыла. 4. Балыкларның саңак яфракчыкларында бик вак кан тамырлары - капиллярлар күп. 5. Еланнарның барысы да, шул исәптән агулылары да, зарарлы кимерүче хайваннарны аулап, шактый файда китерәләр. 6. Беркадәр вакыт үткәннән соң, кәлтәнең кой-

рыгы яңадан үсә, ягъни регенерация була. 7. Әгәр аквариумдагы балыкларны ашаткан саен нинди дә булса шартлы хәрәкәтләр ясасак, мәсәлән, лампочка кабызсак яки аквариум стенасын шакылдатсак, берникадәр вакыттан соң мондый сигналга балыклар азык бирмәгәндә дә җыела башлый.

ТИҢДӘШ КИСӘКЛӘР

***Тиңдәш кисәкләргә сораулар куегыз. Җөмләнең кайсы кисәкләре тиңдәшләнеп килгән, шуны билгеләгез. Җәнлек, бөҗәк, кош исемнәрен рус теленә тәрҗемә итегез.***

1. Төньяк боланнарын ит, тире, сөт алу өчен үрчетәләр, аларны шулай ук җигеп йөрү өчен файдаланалар. 2. Авыл хуҗалыгы хайваннарын үрчетүдән алынган продукция кешене кыйммәтле туклану продуктлары: сөт, ит, май белән тәэмин итә. 3. Терлекчелек, авыл хуҗалыгы тармагы буларак, бик борынгы заманнардан кешенең кыргый җәнлекләрне кулга ияләштерә, йортлаштыра һәм үз кирәкләре ечен файдалана башлаган вакыттан ук килеп чыккан. 4. Кешне, көмеш сыман кара төлке, чәшкене һәм башка кайбер мехлы җәнлекләрне җәнлек фермаларында үрчетәләр. 5. Ак, кара, көмеш сыман зәңгәрсу, энҗе төсендәге чәшкеләр китереп чыгарылды. 6. Умарта корты, кыргый умарта кортлары, төклетуралар, кырмыска, жайдак, кисмән, мөгез-койрыклар — барысы да элпәканатлылар. 7. Бакчада һәрбер җимеш агачы: алмагач, чия, шомырт чәчәк атты. 8. Без кыр казларын, кыр үрдәкләрен, ак-чарлакларны, карлыгачларны, сандугачларны, торналарны, тургайларны, тукраннарны, кызылтүшләрне, шәүлегәннәрне көтәбез.

ЭНДӘШ СҮЗЛӘР

***Түбәндәге җөмләләрдә эндәш сүзләрне табыгыз. Алар янында тыныш билгесе кую кагыйдәләрен аңлатыгыз.***

1. Җырларым! Сез шытып йөрәгемдә ил кырында чәчәк атыгыз (М. Җәлил). 2. Тор, шәкерт! Життек Казанга, алдымызда бит Казан! (Г.Тукай) 3. Алъяпкычың, дустым, ак икән, ак булса да, салыр чак җиткән (С. Сөләйманова) 4. Яшьлек, гомрең кыска синең, шундый кыска булып тоела... (Һ.Такташ) 5. Якын дустым! Сиңа миннән киңәш шул... (Г.Тукай) 6. Юллар, юллар, мине туган йорттан аерып ерак алып киттегез... (М. Җәлил) 7. Чакырсам да, кошчык, син бу йортка үзең теләп очып кермәссең (М.Җәлил). 8. Агышың, и агымсу, туп-тулы зар, синең ни хәсрәтең, ни моңнарың бар? (Дәрдемәнд) 9. Әй, авыл, син мең шәһәрдән мең кабат ямьле вә хуш... (С. Рәмиев).

КЕРЕШ СҮЗЛӘР

***Кереш сүзләрне табыгыз. Мәгънәләрен аңлатыгыз.***

1. Шулай да агулы үләннәрнең табигатьтә күп таралганлыгы мәгълүм. 2. Мәсәлән, төче суларда яшәүче чукканатлы балыклар, барлык динозаврлар, буынтыгаяклыларның күп кенә группалары юкка чыккан. 3. Кояш нуры энергиясе биогеоценозда төрле формаларга: химик бәйләнешләр энергиясенә, механик һәм, ниһаять, эчке энергиягә әверелә. 4. Төрләрнең барысы да диярлек бер генә типтагы азык белән генә тукланмый, бәлки төрле азык объектларыннан файдалана. 5. Мәсәлән, кайбер төр кошлар, оядагы кошчыкларга кысан була башласа, аларның кайберләрен җиргә ташлыйлар.

Димәк, бу жайлашу гомумән төр өчен файдалы. 6. Шулай итеп, кан йомык түгәрәк буйлап өзлексез рәвештә әйләнеш ясый. 7. Әгәр яшелчәләр авыруга тиз бирепгүчән булса, корылыкны авыр кичерә икән, сезгә, һичшиксез, калий ашламалары ярдәм итәр.

## ЖЫЙНАК ҺӘМ ҖӘЕНКЕ ҖӨМЛӘЛӘР

***Түбәндәге җәенке җөмләләрне җыйнак җөмләләргә әйләндереп языгыз. Иярчен кисәкләрнең ни өчен кирәк икәнен аңлатыгыз.***

1. Грифлар табышларын бик биектән күзләп очалар. 2. Тукран көзен һәм кышын ылыслы агач күркәләренең орлыгын күпләп ашый. 3. Күгәрченнәр шәһәрләрдә һәм авылларда көтү-көтү булып яши. 4. Кәлтә далаларда, урманнарда, 1,5 километрга кадәр биеклектәге тау итәкләрендә кояш җылыта торган коры урыннарда тереклек итә. 5. Карпат таулары урманнарында һәм Кавказда саламандралар яши. 6. Карпсыманнар су усемлекләре һәм төрле умырткасыз хайваннар белән тукланалар. 7. Эшче кортның аяклары серкә җыюга һәм кәрәз күзәнәкләрен ясауга җайлашкан. 8. Елан агуы медицинада дарулар әзерләү өчен файдаланыла. 9. Күпчелек ташбакалар тропикларда тереклек итә.

## ТУЛЫ ҺӘМ КИМ ҖӨМЛӘЛӘР

***Түбәндәге җөмләләр арасыннан тулы һәм ким җөмләләрне табыгыз. Үсемлек исемнәренең рус телендәге эквивалентларын әйтегез.***

1.Алтын камчы урманнарда, аланда, куак арасында үсә. Татарстанның барлык табигый районнарында очрый. Мал-туар бу үсемлекне ашамый диярлек. 2. Күкебаш — «Татарстан территориясендә тулысынча саклауга мохтаҗ үсемлекләр исемлеге”нә кертелгән. Татарстанның яфраклы урманнарында очрый. 3. Кызыл бөрлегән җиләкләрен яңа җыелган килеш ашыйлар. Үләне белән тын бетүне, ашкайнату юллары авыруларын дәвалыйлар. 4. Кипкән канлы үлән ветеринариядә кулланыла. Аның белән йорт хайваннарында тимрәү авыруларын дәвалыйлар. 5. Ала миләүшә Татарстанның бар төбәгендә очрый. Апрельдән башлап көзгә кадәр чәчәк ата. 6. Наратбаш Татарстанда киң таралган, бигрәк тә төньяк районнарда ачы туфраклы җирләрдә күпләп үсә. Медицинада яшел, җимешсез, ботаклы җәйге үсентеләре файдаланыла.

## ГАДИ ҖӨМЛӘ ТӨРЛӘРЕ

***Укыгыз. Сорауны белдергән чараларны табыгыз.***

1. Яшелчә һәм җиләк-җимешләрегез начар үсәме, яфраклары аксыл-яшелгә әйләнеп, хәтта саргаеп, коела башлыймы? 2. Ашламаларны саклау, аларны туфракка кертү вакытын, алар белән эш итү алымнарын, кагыйдәләрен кемнәр белергә тиеш? 3. Бу бөҗәкләрне табигатьтә күргәнегез бармы? 4. Яңгыр суалчанының туфракта яшәүгә җайлашуы аның тышкы төзелешендә ничек чагыла? Әллә күпкә, әллә бик озакка ... Соңгы җырым, бәлки ... шул җырымны багышлыйм соң кайсы дустыма? (Һ. Такташ) Ә мин белмим, сыерчык кешеләр тормышына шатланып сайрыйдырмы, әллә үзенең зәңгәр оясын сагынып елыйдырмы (Г.Гыйльманов).

***Өзекне укыгыз. Гади җөмләләрнең төрләрен билгеләгез.***

Озын кышны чыккан һәм бик нык арыган, хәлсез кошлар март аенда аеруча күп үлә. Бу чорда аларны ашатыгыз! Күчмә кошлар өчен оялар әзерләгез! Сез бик зур һәм игелекле эш эшлисез.

Оялары нинди булырга тиеш соң? Оялар нык һәм тишек-ярыксыз булырга тиеш. Аларны теләсә нинди тактадан ясарга ярый. Тик фанер дан гына ясамагыз! Тактаны тышкы яктан гына ышкылыйлар. Эчке як, кошларга оядан чыгарга уңайлы булсын өчен, кытыршы кала.

Күп кенә кошлар багана оялар яраталар. Мондый ояны агачның эчен уеп ясыйлар.

Кошлар матур төсләргә буялган яки яңа гына эшләнгән ояны яратмыйлар. Буярга теләсәгез, ояны куе марганцовка белән буягыз. Ояларны бераз алга авыш итеп, биек җиргә элегез. Кошлар шунда ук очып килерләр.

***Өзекләрне укыгыз. Тойгылы җөмләләрне генә күчереп языгыз.***

1. Иртәгесен кызарып кояш чыкты. Табигате дә әллә сизә инде. Сабан туена нинди матур көн! (Р.Низамова). 2. Җылылык һәм дым - апрель климатының төп ике байлыгы - агачларга һәм үсемлекләргә яшәү сулышы өрә. Урманнар, болыннар, яр буйлары беренче чәчәкләр белән бизәлә. Әнә үги ана яфрагының сап-сары чәчәге нәни кояш сыман балкып утыра! (Х.Махмутов) 3. Тегермән буасы! Бала чагыбызга күпме шифа, күпме серле моң бүләк иттең син безгә?! Сәгатьләр буе чыкмыйча су коенулар... Чабак, кызылканат, бәртәс бик әйбәт чиртә иде анда... Йа, балыкка нихәтле бай, нихәтле юмарт иде ул буа! Ничек йөрәккәйләрең җилкенмәсен! Менә хәзер, Ык, Чирмешән кебек зуррак елгаларга барып та, минем ул чактагы кадәр уңыш белән кайта алганым юк (Р.Төхвәтуллин). 4. Ак төнбоек! ... Исемгә бай ул төнбоек. Ак ләлә исемле дә ул. Су гөлчәчәге дә ул. Хәтта нимфея дә. Берсеннән-берсе матур исемнәр! Соңгысы - борынгы греклардан чыккан сүз. Имеш, бер сылу нимфа ак төнбоекка әйләнгән. Легенда инде бу! Тик аның легендага керүенә гаҗәпләнер урын юк: шулчаклы гүзәл чәчәккә борынгылар да сокланмый булдыра алмаганнар. Һәр чәчәк уртасында бер кояш! (Г. Хәсәнов)

## РАСЛАУ ҺӘМ ИНКЯР ҖӨМЛӘЛӘР

***Мисаллардан раслау һәм инкяр җөмләләрне аерып күрсәтегез. Инкяр күрсәткечләрен әйтегез.***

Судан башка яшәү мөмкин түгел. Сусыз иген үсми, заводлар, фабрикалар эшли алмый. Бер тонна кирпеч ясар өчен, ике тонна су кирәк. Бер тонна металл коюю өчен, 300 тонна су кирәк. Авыл хуҗалыгы өчен, су тагын да күбрәк кирәк. Бер тонна мамык үстерү өчен 10000 тонна су кирәк. Бер тонна бодай үстерү ечен 1500 тонна су кирәк. Бер тонна мамык үстерү ечен 10000 тонна су кирәк.

Кешегә, хайваннарга, үсемлекләргә чиста, табигый су кирәк. Елгалар, буалар, күлләрне заводлар, фабрикалар пычратса, су зарарлы һәм агулы була. Аны эчәргә ярамый, аның белән кырларны сугарырга ярамый. Пычрак суда балык үлә, елга буенда үсемлекләр корый.

Кешеләр диңгез буенда ял итәләр. Су кешене тынычландыра. Диңгез, күл буйларында ял йортлары, санаторийлар төзелә.

## ГАДИ ҺӘМ КУШМА ҖӨМЛӘ

***Өзекләрдән гади һәм кушма җөмләләрне табыгыз. Гади җөмләләрне генә сайлап, дәфтәрегезгә языгыз.***

Пингвиннар балык, башаяклы моллюсклар һәм кысласыманнар белән туклаланалар. Нигездә, алар Антарктидада тереклек итәләр. Пингвиннарның иң зурысы — император пингвины, аның буе 120 сантиметрга, массасы 45 килограммга кадәр җитә. Пингвиннар колония булып оялыйлар. Салкынга чыдамлыклары буенча болар җирдә иң чыдам хайваннардыр. Мәсәлән, император пингвины үзенең баласын чиктән тыш салкын вакытта — температура -60... - 70° чыгара.

Антарктидада яшәп, пингвиннар соңгы вакытларга кадәр кешеләр белән очрашмаганнар, шуңа күрә алар кешедән бөтенләй курыкмыйлар. Киресенчә, бик кызыксынып, алар фәнни-тикшеренү станцияләренә киләләр, поселок буйлап иркенләп йөриләр, йортларның эчен карыйлар, хәтта трап буйлап судно палубаларына да меңәләр.

Аккошлар авырлыклары 12 килограммга, канатларын җәйгәндә 2,5 метрга җитә торган тез гәүдәле зур кошлар. Бездә өч төре бар. Ата һәм ана кошларның икесенең дә каурыйлары ап-ак төстә. Елга үрдәкләре кебек үк, сай сулыкларда, башлары белән чумып, елга төбендәге умырткасыз хайваннар һәм суусемнәр белән туклаланалар. Йомырка өстендә ана аккош утыра, ә атасы якын-тирәдә йөреп тора, ояны саклый, башка аккошларны куып җибәрә. Парлары гомер буе саклана. Хәзерге вакытта аккошлар аз калды. Кече аккош Кызыл китапка кертелгән. Буалары булган парклы кайбер шәһәрләрдә аккошларны декоратив кош буларак асрыйлар.

Күп кенә үрдәк һәм казлар кыйммәтле промысел кошлары булып исәпләнәләр. Алар халык хуҗалыгына тәмле ит белән йон һәм мамык бирәләр.

## БЕР СОСТАВЛЫ ҖӨМЛӘЛӘР

***Бер составлы җөмләләрне табыгыз. Төрен әйтегез.***

1. Кояш... Ул да соңгы минутында мәхрүм итте мине нурыннан (М. Җәлил). 2. Кич иде. Шатлык белән нурлар чәчеп ай ялтырый (Г.Тукай). 3. Алар... Алар җыйнап аналарны, балаларны кырга кудылар (М.Җәлил). 4. Ул шәһәр — гади шәһәр, алтын- көмеш, гәүһәр түгел... Г.Тукай). 5. Һәр тараф тын. Уй миңа тик әллә ни җырлый, укый (Г.Тукай). 6. Төн. Ае юк төннең (Һ.Такташ). 7. Язгы аяз көн. Күктә елмаеп кояш балкый (В. Исхаков). 8. Яңгыр. Гел яңгыр. Әле яшенлесе камчылап китә, әле томанлысы сибәли (Ә. Гаффар).

***Бер составлы җөмләләрне языгыз. Мисаллар фигыль җөмләнең кайсы төренә китерелгән?***

1. Кайберләрен, мәсәлән, ондатраны, матур мехы өчен аулыйлар. 2.Безнең илгә аны ярты гасыр чамасы элек алып кайтып тараттылар. 3.Беловеж урманнарында һәм Окск тыюлыгында зубрлар үрчетәләр. 4. Безнең эрага кадәр 7000 еллар чамасы элек Грециядә турны йортлаштырганнар дип исәплиләр. 5. Кайбер өлкәләрдә җирле шартларга яхшы җайлашкан башка токымнарны да үрчетәләр. Мәсәлән, Холмогор, Ярославль токымнарын. 6.Ит токымына шулай ук Калмык токымын да

кертәләр. 7. Сөт җитештерү фермаларында терлекләрне һәрвакыт биналарда тоталар. 8. Кешне, кемеш сыман кара төлке, чәшкене һәм башка кайбер мехлы җәнлекләрне җәнлек фермаларында үрчетәләр.

***Бер составлы җөмләләрне табып, төрләрен әйтеп чыгыгыз.***

1. Бар җырымны илгә багышладым, Гомеремне дә бирәм халкыма (М. Җәлил). 2. Яктыра башлады. 3. Аерыласы килми иде аның бу тын биеклектән, яңа хисләр дулкынынннан (Ә. Еники). 4. Учлап чәчсәң, йөкләп алырсың. 5. Кырымга бару белән, безне отрядларга бүлделәр (А. Гыйләҗев). 6. Амбарың белән мактанма, ашлыгың белән мактан. 7. Кара бөтнекне плантацияләрдә үстерәләр. 8. Бу арада суытып җибәрде (М.Мәһдиев). 9. Суганны төрле авыруларга каршы файдаланалар.

## ПРАКТИЧЕСКОЕ ЗАНЯТИЕ №2
## «СИНТАКСИС СЛОЖНОГО ПРЕДЛОЖЕНИЯ»

**Цель занятия:** получение теоретических и практических знаний по синтаксису сложного предложения

### Сложное предложение (Кушма җөмлә)

Сложное предложение – это предложение, имеющее две или более грамматические основы. Отдельные предложения, входящие в состав сложного, образуют смысловое, грамматическое и интонационное единство.

По характеру связи между отдельными предложениями они бывают сложносочиненные (тезмә кушма җөмлә) и сложноподчиненные (иярченле кушма җөмлә).

Сложносочиненные предложения состоят из двух или нескольких предложений, соединенных между собой интонацией или сочинительными союзами, выражающими соединительные, противительные, разделительные отношения. Союзная связь более характерна для письменной книжной речи, в то время как в устной речи употребляются сложносочиненные предложения без союзов, т.е. связанные между собой соединительной и противительной интонацией.

Союзное сложносочиненное предложение (теркәгечле тезмә кушма җөмлә) – предложение, части которого связаны менду собой сочинительными союзами. В таких предложениях средством связи выступают сочинительные союзы: 1) соединительные *һәм (и), вә (и), -да-дә, -та-тә, тагын (еще), ни...ни (ни...ни), әле...әле (то...то)*; 2) противительные *-ә (а), ләкин (но), тик (однако), әмма (но), фәкать (только), бары (только)*; 3) разделительные *– я, яки, яисә (или; или...или), әллә...әллә (то ли...то ли)* и т.д. : Мин килдем*, һәм* дәрес башланды.

В сложноподчиненном предложении одно предложение подчиняется другому. Предложение, которое подчиняет себе другое, называется главным (баш җөмлә), а подчиненное – придаточным (иярчен җөмлә). В татарском языке, в отличие от русского языка, в зависимости от средства связи, сложноподчиненные предложения бывают двух видов: аналитические и синтетические. К аналитическим средствам связи относятся подчинительные союзы,

союзные и относительные слова и интонация ожидания.

Подчинительные союзы и союзные слова (иярткүче текәгечләр һәм теркәгеч сүзләр): *чөнки (потому что), әгәр (если), әгәр дә (если бы), гүя (будто), гүяки (будто), гәрчә (несмотря), ки (что), әйтерсең (словно), диярсең (будто), ягъни (то есть), бигрәк тә, аеруча (особенно) и т.д.:* Урамда шундый җылы, *гүя* яз җиткән.

Относительные слова (мөнәсәбәтле сүзләр) бывают парные и относительные. Парные: *кем-шул, кемгә-шуңа, кемне-шуны, кайда-шунда, кайдан-шуннан, кайчан-шунда, нинди-шундый, ничек-шулай и т.д.*Одинарные: *шул, шуннан, шундый, шушы, менә нәрсә, менә ничек; бер, югыйсә и т.д.*: Безнең киңәшебез *шундый:* тырышып укырга кирәк.

Интонация ожидания (күтәрү интонациясе) является единственным средством при отсутствии относительных слов и подчинительных союзов/союзных слов: Хәл ителде: мин иртәгә китәм.

Задания для обучающегося:

1. Тезмә кушма җөмләләрнең төрен билгеләгез, бәйләүче чараларны атагыз.

1. Бик биектә сыек ак болыт дулкыннарына тия-тия очты торна, ә тавышы бөтен күк гөмбәзен иңрәтеп таралды. (А.Г.) 2. Иптәшләре чөгендердә эшләде – чыкмады. (А.Г.) 3. Болытлар таралдылар, һәм көн матурланды. 4. Салкын җил исә, яңгыр ява. 5. Әле яңгыр ява, әле кар ява. 6 Яз аена кердек, ә көннәр һаман салкын. 7. Кояш чыкты, ләкин көн җылынмады. 8. Көчле  җил исте – яңгыр яумады. 9. Я татар телендә шигырьләр укыла, я җырлар башкарыла иде. (Р.М.) 10. Көз җитте, басулар бушап калды.

2. Мәкальләрне аналитик иярченле кушма җөмлә итеп языгыз.

1. Коралын тапкан – таш кискән. 2. Хезмәт итә белмәгән – хуҗалык итә белмәс. 3. Бер көн эшен калдырган биш көндә дә куып җитә алмас. 4. Күтәрә алмаган олы күсәк күтәрер. 5. Диңгездә йөрмәгән – куркынычны күрмәгән.

*Үрнәк: Күп эшләгән күп алыр (М.) – Кем күп эшли, шул күп алыр.*

3. Җөмләләрнең нинди төзелештә икәнен (тезмә кушма җөмлә, иярченле кушма җөмләнең синтетик яки аналитик төрен) аңлатып бирегез.

1. Кар оча, кар себрелә, кар котрына һәм кар ява. (Г.Т.) 2. Кем сабыр, шул эшнең җаен табыр. (М.) 3. Моны ул үзе дә белми, башкалар да сөйләмиләр. (Г.И.) 4. Янә күк күкрәде, янә яшен яшьнәде. (М.Ә.) 5. Җил кайдан иссә, болыт та шуннан килә. (М.) Кем тырыша, шул максатына ирешә. 6. Үләннәр корыган, яфраклар саргайган, җил ыңгыра. (Ш.К.) 7. Бу җирнең суы күп, бозы күп – бер бөртек туфрагы, җире юк. (Ә.Ф.) 8. Ике кулың ни эшләсә, ике иңең шуны күтәрер. (М.) Кырдагы арыш чүмәләләре инде кибәнгә куелган, чәчү тәмамланган иде. (М.М.) 9. Каеннар бигрәк тә нәфис, әйтерсең аларның ботакларын энҗеле ак ефәк белән ураганнар. (Г.Ә.) 10. Яз

яме чәчкә белән, көз яме көлтә белән. (М.)

4. Күчереп языгыз. Мөнәсәбәтле сүзләрнең астына сызыгыз.

1. Билгеле ки, мәкальләр иҗтимагый тормыштан башка туа алмый. (Н.И.) 2. Мин шуны гына беләм: ел елга охшамый. (Г.Т.) 3. Ни чәчсәң, шуны урырсың. (М.) 4. Ни хәтле күп булса, шул хәтле яхшы. (Ш.К.) 5. Кояш шулкадәр мул: еракта, еракта әллә ничә офык ясалган. (Ә.Е.) 6. Кыш якынлашып килүгә карамастан, бакчалар чәчәккә күмелеп утыра. (М.Ю.) 7. Чагылларда имән ничек үссә, үз җиремдә шулай үскәнмен. (Ф.К.) 8. Тиз китик без шунда, кайда җәелгән ямь-яшел кырлар, болыннар. (Г.Т.) 9. Бәхетле шул баладыр, кайсы дәрсенә күңел бирсә. (Г.Т.) 10. Түләве нинди, эше шундый. (М)

5. Кушма җөмлә компонентларының нинди чарала аша үзара бәйләнешкә керүен аңлатыгыз.

1. Тургайлар өзлексез сайрадылар, чикерткәләр бер-берсен уздырырга тырышып чыркылдадылар. (А.Г.) 2. Корылык аркасында үлән яхшы үсмәде, бары Үрге әрәмәнең инеше буйларында гына үлән яхшы үсте. (Ш.К.) 3. Җидегән чишмәләргә йөзек салдым, Җидегән йолдыз күреп калсын дип. (Г.Б.) 4. Чыдам булулары аркасында, табан балыклар башка балыклар яши алмаган шартларда да яшиләр. 5. Чәчәге энҗе чәчәккә дә охшаган кебек, ләкин нарат җиләгендә алар салынма чукка җыелган һәм төзелеше белән дә аерыла. 6. Акчарлак килмичә, яз булмый. (М.) 7. Көз җитте, ләкин көннәр әле кояшлы, матур. 8. Яңгыр яуса, тузан басылыр иде. 9. Мин килдем, һәм дәрес башланды. 10. Көн яктырды, һәм бар табигать җанланды.

## СПИСОК ИСПОЛЬЗУЕМОЙ ЛИТЕРАТУРЫ

1. Фаттахова, Р.Ф. Практический татарский язык / Методическое пособие для изучающих татарский язык / Р.Ф. Фаттахова. – Казань: Татар. кн. изд., 2012. – 176 с.

2. Фәтхуллова, К.С. Татарча сөйләшик = Давайте говорить по-татарски = Letsspeaktatar: укуәсбабы / К. С. Фәтхуллова, Ә.Ш. Юсупова, Э.Н. Денмөхәммәтова; [Д.Р. Шәрифуллина тәрҗ.]. – Казан : Татар. кит. нәшр, 2012. – 311 б.

3. Татар фольклоры теле: мәкальләр, канатлы әйтелмәләр, җор сүзләр, әйтемнәр: сүзлек / К. Р. Галиуллин ; ред. К. М. Миңнуллин ; Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты. - Казан : ТӘҺСИ, 2018. - 588 б. - ISBN 978-5-93091-281-4